ISSN 0868-4545



Салават күпере



Игътибар! Бәйге дәвам итә!

Шүрәле малае Шүркә



Шүрәле шарт куя...

Шамил җырлый-җырлый юлын дәвам иткән. «И-лә-лә, и-лә-лә, мин Шүркәне күрәм. Аның койрыгын каптырам да, мөгезеннән тотам!» – ди икән ул. Озак та үтмәгән, аңа бик матур бер бина күренгән. Бинаның ишек төбендә Шүрәле: «Кая барасың, дустым?» – дип үзе басып тора, ди.

– Миңа Шүрәле малае Шүркә кирәк иде. Минем аны күрәсем, койрыгын, мөгезен тотып карыйсым килә, – дигән малай.

– Ә син укырга, язарга яратасыңмы? – дигән Шүрәле.

– Юк, минем укыйсым килми, – дигән Шамил.

Шүркә әйткән:

– Безнең сиңа бер шартыбыз бар: әгәр дә шушы мәктәптә белем алсаң, без сиңа койрыкны да, мөгезне дә тоттырабыз.

Шамил риза булган. Мәктәптә белем алган, күп укыган, күп белгән. Тырыш, акыллы, тыңлаучан малайга әйләнгән. Хәтта Бердәм Дәүләт имтиханнарын да яхшы билгеләргә генә биргән. Шамил бу эшенә үзе сөенгән. Ул Шүрәле малае Шүркәгә рәхмәт әйткән. Шүрәле малае Шүркәнең койрыгын каптырасы, мөгезеннән тотасы да килмәгән. Киләчәктә бары тик яхшы гамәлләр генә эшләячәкмен, дип уйлаган.

Айнур ЗАКИРОВ, 12 яшь.
Азнакай, Әсәй.



Эльвира ГАЙНЕТДИНОВА , 9 яшь.
Алабуга.



Илсөяр ШӘЙГАРДАНОВА, 12 яшь.
Альбина ШӘЙГАРДАНОВА, 10 яшь.
Мөслим, Урәзмәт.

Курку

Шамил урманга килеп керүгә, кич җиткән, караңгы төшкән. Шамил бик курыккан. Аның каршысына үзе озын, үзе ямьсез Шүрәле малае Шүркә килеп чыккан.

– Исәнме, Шамил, мин сине көттем, – дигән Шүркә. – Син дә бабаң кебек эшләячәксеңме?

Шамил бернәрсә дә аңламаган, чөнки аның беркайчан да әкиятне укыганы булмаган. Аның курыкканын күреп, Шүркә тагын да ныграк куркытырга уйлаган:

– Йә, тизрәк исеңә төшер, югыйсә мин сине кытыклап үтерәм, – дигән.

Шамил Шүркәгә ялынырга тотынган:

– Зинһар, миңа тимә, нәрсә телисең, шуны сора, бирәм, – дигән.

– Миңа синнән бернәрсә дә кирәкми? Бүгеннән башлап тәртипле булырмын, мәктәпкә йөрермен, дип сүз бир, – дигән Шүркә.

Шамил ул әйткәннәрнең барысын да кабатлагач, Шүркә аны кайтыр юлга озатып куйган. Ә кайбер көннәрдә, сиздермичә генә килеп, Шамил сүзендә торганмы, юкмы икәнлеген тикшереп йөри, ди.

Илгина САМАТОВА, 7 яшь.
Актаныш, Солтангол.

Кубрат компьютерына ия табылмады!

Кадерле балалар!

Журналыбызның узган елгы саннарының берсендә (№ 10, 2007 ел), күренекле шагыйрь Гәрәй Рәхимнең иҗатына багышланганында, болай дип язган идек: “Гәрәй Рәхимнең бер улы Кубрат исемле. Гәрәй абый аны безнең болгар бабаларыбыз хөрмәтенә кушкан икән. Сезнең мәктәптә ханнар исемен йөрткән малайлар бармы? Булса, язып җибәрегез. Иң уңышлы хат авторына Кубраттан – компьютер!”

*Журналханәгә хатлар күп килде. Әмма, ни кызганыч, ул хатларның берсе дә журнал таләпләренә җавап бирерлек булмады. Мәсәлән, Яңа Чишмә районының Тубылгытау авылында яшәүче укучыбыз **Римма Сөнгатова** үзенең язмасында мәктәпләрендә Алмаз белән Сөембикә исемле балалар укуы хакында әйтеп кенә уза. Шунысы сөендерде: Римма тарихны әйбәт белә икән – Алмас хан һәм Сөембикә-ханбикә хакындагы өстәмә язмасы шул хакта сөйли. Без аңа һәм шундый ук рухтагы язмасы өчен Сарман районы кызы **Зөлфия Газизовага** (Җәлил бистәсе) редакциянең истәлекле бүләкләрен җибәрергә булдык.*

Шулай итеп, Кубратның компьютерына ия табылмады. Күңелегезне төшермәгез, дуслар, без сезгә яңа бәйгеләрне гел игълан итеп торабыз. Шәт, иншалла, шул бәйгеләрдә катнашып, арагыздан кем дә булса, әлеге компьютерга хуҗа булып куймагае!

Уңышлар телибез сезгә!



Тукай дәресләре

Апрель ае – Тукай ае. Чынлап та шулай:

Апрель, апрель... Чәчкәләрне
Сагынып көткән ай да.
Апрель, апрель... Халкыбызны
Тукайлы иткән ай да.

Мәшһүр Тукай абый, аның үлемсез әсәрләре – һәрвакыт безнең күңел түрендә. Без аның әкиятләрен, хикмәтле хикәяләрен кабат-кабат укыйбыз. Әдипнең һәр язганы күңелле, кызыклы вә мәгънәле дәресне хәтерләтә. Без ул дәресләрдән үзебезгә сабак алабыз...

Йәле, дускай, син дә "Тукай дәресләре"нә рәхим ит!

Әлифба



Бер бала атасына:

— Әти, син үзең күзлек киеп китап укыйсың бит, миңа да бер күзлек алып бирсәнә, мин дә китап укыр идем, — диде.

Атасы:

— Ярар, угылым, мин сиңа күзлек алырмын, ләкин ул балалар күзлеге генә булыр, — дип, угылына бер әлифба китабы алып бирде.

Һәрнәрсәнең үз урыны бар

Габдулла, йокысыннан уянды исә, үзенең кием-салымын аннан-моннан эзләргә тотына.

Аның бер читеге урындык астында, икенче сыңгары өстәл астында ята. Бүреге карават астында ауный, кәләпүше бүлмәдә үк юк.

Габдулла һәр иртә белән шул баш, аяк киемнәрен эзләп маташа да һәр көн сабакка соңга калып килә.





Һәркем эштә



Борһанетдин: «Мин бүген сабакка бармыйм; анда барганчы, кырларга чыгып уйнармын», — дип, басу капкасыннан җөгереп чыгып китте.

Борһанетдин кырда бер Атны күрде. Ул тиз генә Ат янына барды да: «Әйдә, Бахбай, икәү уйныйк, күңел ачыйк», — диде.

Ат:«Юк, җаным, минем уйнарга вакытым юк; минем сабан сөрәсем бар, Хуҗама хезмәт итеп ризык табасым бар, син үзең генә уйнарсың», — дип җавап бирде.

Бала, моннан киткәч, Умарта кортын күрде.

Ул аның янына да барып: «Әй, Умарта корты! Әйдә икәү уйныйк, күңел ачыйк», — диде.

Умарта корты да җавабында: «Юк шул, минем эшем бар, җәй көннәре тиз үтеп китә. Минем көзгә кадәр төрле чәчәкләрдән ашыгып-ашыгып бал җыеп каласым бар, үзең генә уйна», — диде.



Борһанетдин, аптырагач, бер Кош янына барып, аның үзе берлә уйнавын үтенде.

Кош та, Борһанетдиннең үтенечен кабул итмичә: «Юк, бала, минем уйнарга вакытым юк; кечкенә балаларыма ашатыр өчен чебен-черкиләр аулыйсым бар», — диде.

Болай да булмагач, Борһанетдин тирән уйга чумды да тиз генә мәктәпкә таба җөгерде.

Дускай!
Бу хикәятләрне исеңдә калдыр һәм, үзеңчә итеп, өлкәннәргә кабат сөйлә. Ничек уйлыйсың, Тукай абый бу хикәятләрдә ни әйтергә теләде икән? Үзеңчә аңлатып кара әле, яме!





Рәссам Диләрә НӘУРУЗОВА



Сокландым

Күптән түгел безнең Ленино-Кокушкино урта мәктәбенә “Сорнай” ансамбле кунакка килде. Миңа аларның чыгышы бик ошады. Бу ансамбль татар халкының матур-матур җырларын җырлады. Артистларның биюен, уен коралларында уйнавын мин, шундый бирелеп, гаҗәпләнеп, сокланып карап утырдым.

Безне күңелле ял иттергәннәре өчен “Сорнай” ансамбленә бик зур рәхмәт!

Динә ЗЫЯТДИНОВА, 13 яшь.
Питрәч, Ленино-Кокушкино.

2008 ел — Гаилә елы.

Шул уңайдан, Казандагы 122 нче мәктәп укучылары матур-матур рәсемнәр ясаганнар.



Ринат ШӘРӘФИЕВ, 9 яшь.



Мәдинә КӘБИРОВА, 9 яшь.



Инсаф КАШАПОВ, 9 яшь.



Эльмира ХУҖИӘХМӘТОВА, 9 яшь.



Регина МӨЛЕКОВА, 9 яшь.



Камилә ӘХМӘТШИНА, 9 яшь.

Әтием авылы

Әтием туган авылның
Гүзәллеге җитәрлек;
Су буйлары, урманнары –
Бар да гашыйк итәрлек.

Аның чиста, саф һавасы
Һәр кешегә көч бирә.
Соклanyрлык авыл, диеп,
Сөйлиләр шуңа күрә.

Римма ШӘЕХОВА, 14 яшь.
Азнакай.

Куян кызы

Яшәгән, ди, бер куян кызы. Ул көн саен күл янына килә икән дә: "Мин нинди матур, мин нинди чибәр!" – дип, үз-үзенә сокланып җырлап утыра икән. Күлдәге бакалар да җырларга яратканнар. Алар беркөнне төнбоек яфракларына утырып: "Без нинди чибәр, без нинди матур", – дип җырларга тотынганнар. Куян кызы бик үпкәләгән: ничек инде бакалар куян кызы кебек чибәр булсын!? Ул борынын чөйгән дә, күл буеннан горур гына китеп барган. Бакалар, әлбәттә, аңа үпкәләп тормаганнар, алар Куян кызын акылга гына утыртырга теләгәннәр. Алганнар, ди, әбиләре Гөберлебикәнең зур фотосурәтен, шуңа колаклар, мыеклар, койрык өстәп куйганнар, ди.

Икенче көнне Куян кызы янә күл буена килгән һәм үзенең судагы сурәтенә караган. Ә анда аңа таба зур яшел колаклы, мыеклы, яшел йөзле бер җан иясе карап тора икән. Куян кызы башка җиргәрәк китеп караган, анда да шул ук хәл икән. Ул ачудан суга таш аткан, тик су тынычлануга, шул ук сурәт кире кайткан.

Шуннан соң бакалар судан чыкканнар да куянкайга карап җырлый башлаганнар: "Син нинди чибәр, син нинди матур, нәкъ безнең шикелле!"

Куян кызы җырның ахырынача түзеп тора алмаган, урман эченә йөгергән. Һәр почмактан аңа күлдәге сурәт карый сыман тоелган. Шуңа аның күзләре кылыйланып калган, ди. Үзе куркакка әйләнгән, ди.

Шат күңелле бакалар тәкәббер куян кызын менә шулай кызык иткәннәр.

Алисә ЗАРИПОВА.
Казан.



Борис ВАЙНЕР

Чудесная книга

Самая чудесная –
Эта книга в мире:
В ней картинок много,
А страниц – четыре.

Первая – белая,
Тихая страница,
Где медведю сладко
В снежном доме спится.

Дальше – голубая,
Звонкая страница,
Где висит сосулька
И ручей струится.

А за ней – зеленая.
Жаркая страница,
Где сидит на ветке
Солнце, будто птица.

А за нею – желтая,
Грустная страница.
Где листок кленовый
В воздухе кружится.

В воздухе кружится,
Под ноги ложится...
Прочитаешь книгу –
Год промчится.



Рәссам Алла АЙСИНА



Искиткеч китап

Дөньяда ул – иң гаҗәеп,
Иң искиткеч бер китап:
Дүрт кенә битле булса да,
Рәсемнәре – бихисап!

Иң беренче ап-ак биттә,
Ак тынлыкны иш күреп,
Кар өендә аю йоклый –
Тәмле-татлы төш күреп!

Икенче бит – зәңгәрсу бит,
Яңгыравыклы бит тә:
Тып-тып тамган тамчы җыры
Күңелгә якын бик тә!

Күр, өченче яшел биттән
Эссе бөркелеп тора:
Ботакка кунган кош-кояш
Елмаеп, көлеп тора!

Соңгы сары биттән, гүя,
Моңсулык ташып тора:
Яфракларны җил каядыр
Куалый – ашыктыра.

Яфракларны җир өстеннән
Җил һаман куып йөртә...
Китап укылып беткәндә,
Ел инде узып китә.

Русчадан Ләбиб ЛЕРОН тәрҗемәсе



Мин бит бу?!





Ралинә, 4 яшь 7 ай

– Яңа ел да бу юлысы
Килгән булды көттереп...
Ялындырып утырмале,
Әйдә, биик теттереп!

Актаныш, Татар Суыксуы.





Раян, 6 яшь
Ранис, 2 яшь

– Без эштән курыкмыйбыз,
Ял итәрбез арысак...
Көне буе су сибеп,
Үстерәбез сарымсак.

Буа, Бикмураз.



Ислам, 1 яшь

– Тәрәз төбенә утырып
Көннәрем үтә:
Әти-әниемнең эштән
Кайтканын көтәм!

Балтач, Борбаш.



Динә, 6 яшь
Диләрә, 4 яшь

"Сез нишлисез, балалар?" – дип,
Йәгез, бездән сорагыз...
– Күрмисезмени, иптәшләр,
Юл күрсәтеп торабыз!

Теләче, Алан.





Раилә, 3 ай



– Сезне каян тапканнардыр –
Анысын белмим инде...
Кәбестәләр арасыннан
Табып алдылар мине!

Казан.



Риназ, 5 яшь

– Шатлык-куанычымны
Сезгә дә әйтим әле:
Озакламый өйгә кайтам –
Котегез, әти, әни!

Казан.


Нәфисә, 3 яшь

– Эшләп тә күрсәттем инде –
Сыңар чүп тә калмады.
Ни хикмәттер: беләкләрем
Аз гына да талмады.

Казан.


Эльза, 5 яшь

– Өй артында – чәчәкләр,
Тәрәз төбендә – гөлләр...
Кайсы гөл матур икәнен
Әйт әле – үзең бел дә!

Минзәлә, Аю.






Илсинә, 8 ай

– Әни дә юк янымда,
Әти дә юк янымда...
Ник ашатмыйсыз инде –
Чакырыгыз табынга!

Балтач, Алан.


Алинә, 7 яшь 7 ай

– Безнең өйдә зур бәйрәм –
Килде янә Яңа ел...
Шул уңайдан сурәткә
Төштем әле елмаеп.

Актаныш, Татар Суыксуы.







Синең исемең ничек?

Сезнең гаиләдә кемнәр бар? Мәсәлән, безнең гаиләдә әби, бабай, әти, әни, абыем һәм мин бар. Минем исемем – Зиннур.

“Зиннур” исеме нәрсә аңлатканын мин беләм. “Зин” – асыл, кыйммәтле таш, дигән сүз. Димәк, “Зиннур” асылташ нуры була.

Ә синең исемең ничек? Ул нәрсә аңлата? Гомумән, гаиләгездәге бар кешенең дә исемнәре нәрсә аңлата? Шул хакта безгә язып җибәр.

Бәлкем, сезнең өйдә эт, песи кебек җан ияләре дә бардыр? Аларның кушаматлары (мәсәлән, Акколак, Муйнак) ни аңлата?

Иң матур хат авторының гаилә фоторәсеме журналда урын алачак! Шуңа күрә конвертка гаилә рәсемен дә салырга онытма!

Хәзер бер шигырьдән өзек тәкъдим итәм. Ул кем шигыре? Шигырьне тулысы белән ятла.

...Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле,
Ул минем дәү әнием...

Зиннур ХӨСНИЯР.



Яңа бәйге!
«Иң матур песи – минем песием!»

Дускай!

Әгәр дә өеңдә песиең бар икән, бу бәйге нәкъ сиңа кагыла!

Песиеңнең шаянлыклары хакында хат язып җибәр! Ул песине өегездә кем тәрбияли, кем ашарына сала?

Моннан нәкъ 15 ел элек “Салават күпере” “Мисс-Песи” бәйгесе оештырган иде. Редакция йөзләрчә хат алды. Һәр бала үзенең песие белән төшкән фоторәсемен җибәрде. Ул фоторәсемнәр журналыбыз битләрендә урын алып барды.

Бәйгедә Казаннан Лиана исемле кыз җиңүче булды. Шуннан соң Лианага (хәзер аңа 25 яшь!) яшьтәшләреннән дистәләрчә хатлар килгән. Лиана хат аша яңа дуслар тапкан! “Песием аркасында иң якын дусларымны таптым! Рәхмәт песиемә!” – дигән иде ул.

Син дә песиең белән бергә яңа дуслар тап!

Үз песиең белән бергә төшкән фоторәсемнәр конкурсында катнаш!

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ







Әни кадак кага, әти бияләй бәйли

Безнең өйдә һәркем ни дә булса эшли. Мәсәлән, бабай көн саен ашарга әзер-ли. Бүген безгә тәмле бәлеш пешереп ашатмакчы. Әни балта-чүкеч белән эш итәргә ярата. Әле менә, картина эләр өчен, стенага кадак кагып маташа. Әби телевизор каршында мәш килә. Ул бик бирелеп футбол карый. "Рубин" җиңә! - дип, сөенеп утыра. Әти көн саен бәйләм бәйли. Әнә, үзенә дигән бияләйнен очына чыгып килә инде. Абый да эшсез түгел. Ул көзге каршында бизәнеп утыра. Сеңлем ишегалдында кар көрәгән бугай. Көрәген ялгыш өйгә алып кергән.

Мин дә эшсез тормыйм. Менә шушы хатны язам...

Айрат ВӘЛИЕВ, 8 яшь. Мөслим

Кадерле дускай!

Сизгәнсеңдер инде, Айрат, әллә чынлап, әллә юри, хатында күрәләтә ял-гышлыклар җибәргән. Рәсемгә карап ул ялгышлыкларны тап, яме!



Шагыйрь бәйрәме дәвам итә

Ошбу елның февралендә Татарстанның халык шагыйре Фәнис абый Яруллинга 70 яшь тулды. Әлеге уңайдан, башкалабыз Казанда һәм республикабызның бик күп төбәкләрендә, мәктәпләрдә олпат Шагыйрь абыйның иҗат кичәләре гөрләп узды. Әдипнең күркәм бәйрәме әле дә дәвам итә.

Казанның Совет районындагы 15 нче мәктәп укучылары (укытучылары Фидания Нургаян кызы Леронова) күптән түгел Фәнис абыйда кунакта булдылар. "Яралы язмышлар" әсәрен укып өйрәнгән укучылар Шагыйрь абыйдан үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алдылар, әлеге әсәрдән өзекләр сөйләделәр. Фәнис абый аларга киңәшләрен бирде. Соңыннан, бергәләп, фотосурәткә төштеләр.









«Салават күпере» бәйрәме – Ленино-Кокушкинода!

«Салават күпере» – һәр өйдә, һәр җирдә көтеп алынган кунак. Моның шулай булуы бик табигый: «Салават күпере»н яратып укыйлар, нәни укучылар үзләре дә журналны чыгаруда актив катнашалар – шигырь-әкиятләр, матур-матур рәсемнәр юллыйлар. Кунакны кунак итә белгән шундый укучылар белән очрашу – безнең өчен зур бәйрәмгә тиң!

Шундый күркәм бәйрәм-очрашу күптән түгел генә Ленино-Кокушкино мәктәбендә (Питрәч) булып узды. Балалар «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналлары хезмәткәрләре, шагыйрь Ләбиб Лерон һәм журналист Земфира Гыйльметдинова белән очраштылар.

«Салават күпере»н бик ярата икән укучылар. Аларның чыгышларын тыңлагач, үзара гәпләшкәч, шундый фикергә килде Ләбиб абыйлары һәм Земфира апалары. Хәер, моның чынлап та шулай икәнен әлеге фоторәсемнәргә карап та белеп була.

Л. ГЫЙЛЬФАНОВ.







ИНГЛИЗЧӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛ



Plums [пламз] – слива.



Peaches [пи'чиз] – персик.

Do you like ...? [ду ю лайк ...] – Син яратасыңмы?

Do you like plums? – Син слива яратасыңмы?
Do you like peaches? – Син персик яратасыңмы?



Apricots [э'йприкотс] – абрикос.




Pears [пэ'арз] – груша.

Yes [йес] – әйе.
I [мин]

Do you like apricots? – Син абрикос яратасыңмы?
Yes, I like apricots. – Әйе, мин абрикос яратам.
Do you like pears? – Син груша яратасыңмы?
Yes, I like pears. – Әйе, мин груша яратам.



Orange [о'ринидж] – әфлисун.



Nut [нат] – чикләвек.

This [зис] – бу.
Big [виг] – зур.
Small [смол] – кечкенә.

This is an orange. – Бу әфлисун.
It is big. – Ул зур.
This is a nut. – Бу чикләвек.
It is small. – Ул кечкенә.

Would you like ...? [вуд ю лайк ...] – син теләр идеңме (телисеңме)?
Something [са'мфинг] – берәр нәрсә (нәрсәдер).
Eat [ит] – ашарга, ашау.

Would you like something to eat? – Син берәр нәрсә ашарга телисеңме?
Yes. I would like a big red apple. I am very hungry. – Әйе. Мин зур кызыл алма телим. Минем тамагым бик ач (ашыйсым килә).



ЗИЛӘ тексты һәм рәсемнәре



Руфия ҖАМАЛОВА, 7 яшь.
Тәтеш, Кызыл Тархан.





Илназ ИМАМРАЗЫЕВ,
8 яшь.
Актаныш.

15 нче биттәге башваткычның җавабы.





Салават күпере

4(217) — 2008

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал основан в 1990 году.
На татарском языке.

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Иван ВОРОБЬЕВ рәсемнәре.

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә бүленде.

Басарга кул куелды 2.04.2008 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ Т-377.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова.


ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ.


Гомуми тираж 464920 данә
Тираж 11343 данә.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Безнең адрес:
420012 г.Казань, ул.Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

«Идел-Пресс» ААҖ.
Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб ЛЕРОН

Сыерчык оясы

Көн матур: җил исә,
Нур сибә кояшым...
Әйбәтләп ясадым
Сыерчык оясын.

Шат, көләч йөзләрдә,
Күзләрдә көн яме...
Көтәмен, ояма
Сыерчык килгәнен!

